**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» февраль, 2023 ел № 126

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны казначылык белән тәэмин итү очракларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 01 декабрендәге 2155 номерлы карары нигезендә «Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары тарафыннан акчаларны казначылык белән тәэмин итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» (алга таба - 2155 номерлы Карар), РФ Бюджет кодексының 242.26 маддәсе (алга таба - РФ БК маддәсе 242.26) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны казначылык белән озата бару Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнен) финанс органнары тарафыннан 2155 номерлы карары белән расланган акчаларны казначылык озату тәртибенә һәм Россия Федерациясе БК 242.26 статья нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. 50 миллион сумнан кимрәк суммада төзелә торган дәүләт (муниципаль) контрактлары буенча;

1.2. Россия Федерациясе субъектларының бюджет яисә автоном учреждениеләре (муниципаль бюджет яисә автоном учреждениеләр) тарафыннан 50 миллион сумнан кимрәк суммада төзелә торган контрактлар (шартнамәләр) буенча шәхси счетлары күрсәтелгән учреждениеләргә Россия Федерациясе законнары нигезендә керә торган акчалар исәбеннән Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) финанс органында ачылган.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге адрес (www.pestreci.tatarstan.ru) буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Д. Сабитовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Никитин